| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_19_» _04_ 2019 г. № _168_

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру һәм Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген төгәлләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Кушымта итеп бирелгәнне расларга :

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган вәкаләтләр буенча күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлеген (1 нче кушымта).

2.Үз көчен югалткан дип таныргa:

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2018 елның 5 июлендәге 242 номерлы карары.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма
комитеты карарына
1 нче кушымта
19.04.2019 №_168__

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган вәкаләтләр буенча күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлеге**

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты ГХАТ бүлеге тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр**

1. Никахны теркәү.
2. Бала тууны теркәү.
3. Аерылышуны теркәү.
4. Әти булуны билгеләүне теркәү.
5. Исемне үзгәртүне теркәү.
6. Уллыкка (кызлыкка) алуны теркәү.
7. Үлемне теркәү.
8. Граждан хәле актларын язуга төзәтмәләр яисә үзгәрешләр кертү.
9. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар һәм граждан хәле актының булуын яки булмавын раслаучы башка документлар бирү.

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының архив бүлеге тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр.**

10. Дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклanучы архив фондлар буенча архив белешмәләре, архив өземтәләре, архив документлары күчермәләре бирү.
11. Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен файдаланучыга дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклануучы архив документларын бирү.
12. Дәүләт милкенә кертелгән архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү.

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр.**

13. Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтүне оештыруга юнәлдерелгән карарлар бирү.
14. Суд тәртибендә эшкә сәләтсез яисә эшкә яраксыз дип танылган балигъ булмаган зат өстеннән опека яки попечительлек, опекун яисә попечитель билгеләү.
15. Тәрбиягә алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү
16.Балигъ булмаган кеше мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыру өчен опекунга рөхсәт бирү.
17. Опекунга тәрбиягә алынган зат исемендәге торакны наемга тапшыру өчен рөхсәт бирү.
18. Опекунга тәрбиягә алынган затның мөлкәте белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү.
19. Яшәү урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә, опекунга тәрбиягә алынган кешене яшәү урыны буенча теркәү учетыннан төшерү өчен рөхсәт бирү.
20.Опекунга яки попечительгә тәрбиягә алынган затның мирас хокукларына керү өчен рөхсәт бирү.
21.Опекунга яки попечительгә тәрбиягә алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирү.
22. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларда булган эшкә яраксыз гражданнарны вакытлыча тапшыру турында бәяләмә бирү.
23.Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.
24. Балигъ булмаганнар (алар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү.
25. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын уллыкка алучылар булу һәм уллыкка алучылар сыйфатында исәпкә кую мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.
26. Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен алу буенча килешүләр ясауга алдан рөхсәт бирү.
27. Үндүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү.
28. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өстеннән опека билгеләү яки опекун булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү.
29. Балигъ булмаган баланы эмансипацияләү мөмкинлеге турында карар кабул итү (балигъ булмаган баланы тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү).

30. Балигъ булмаган балага карый торган күчемсез милекне алу буенча алыш-бирешләр тормышка ашыруга алдан рөхсәт бирү.
31. Кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залог итеп (ипотекага) тапшыру.
32. Балигъ булмаган балага акчалата ярдәм алу өчен законлы вәкилгә рөхсәт бирү.
33. Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга баланы карап тоту өчен акча билгеләү һәм түләү, шулай ук опекунга яки попечительләргә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга, үз вазыйфаларын башкаручы буларак тиешле түләү дә каралган.